ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

КАРАР

12 ноябрь, 2019 ел №216

Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертергә:

- территориаль Р-1 өлешен (рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы), Ж-2 территориаль зонасы өлешен (азкатлы һәм урта катлы торак йортлар төзү зонасы) һәм Д-3 территориаль зонасын (мәгариф һәм фәнни комплексларны урнаштыру зонасы) «Мир» бакчачылык җәмгыяте территориясе һәм

«Солнышко» бакча җәмгыяте территориясенең бер өлешенә карата, аларда индивидуаль торак йортлар төзү максатыннан Ж-1 территориаль зонасына (индивидуаль торак йортлар төзү зонасы) үзгәртергә;

-ИТ-3 территориаль зонасын (инженерлык инфраструктурасы объектлары зонасы) ТР, Лениногорск ш., Добролюбов ур., 25а адресы буенча урнашкан 16:51:013102:2611 номерлы җир карата карата, факттагы - торак-эксплуатация хезмәтләре өчен куллануга туры китерү максаты белән, Ж-2 (азкатлы һәм уртача катлы торак йортлар төзү зонасытерриториаль зонасына үзгәртергә;

-Ж-3 территориаль зонасын (күпкатлы, алты һәм күбрәк катлы торак йортлар төзү зонасы) һәм Р-1 территориаль зонасының бер өлешен (рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы) ТР, Лениногорск шәһәре, с/о "Луч" адресы буенча урнашкан №16:51:011801:683, №16:51:011801:402 җир участокларына карата, бассей төзү максаты белән, Д-4 территориаль зонасына (спорт һәм спорт-тамаша билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зонасы) үзгәртергә.

2.Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль геомәгълүмат системасында (ФГИС РТ) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://Leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Н. Карасевка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов